КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 июнь г.Казань № 561

2021 елда «Татарстан Республикасында энергия ресурслары нәтиҗәлелеге» дәүләт программасын тормышка ашыру барышы һәм 2022 елга бурычлар турында

Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә дәүләт сәясәтен алга таба тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «2021 елда «Татарстан Республикасында энергия ресурслары нәтиҗәлелеге» дәүләт программасын тормышка ашыру барышы һәм 2022 елга бурычлар турында» Татарстан Республикасы Хөкүмәте хисабын хупларга.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына хисап кварталыннан соң килә торган айның 25енә кадәр бюджет өлкәсендәге республика оешмаларының энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре буенча мәгълүматны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына квартал саен кертүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына:

законнарда билгеләнгән срокларда Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Энергетика ресурсларын куллану турында декларация бирү тәртибен һәм энергетика ресурсларын куллану турында декларация формасын раслау хакында» 2019 елның 28 октябрендәге 707 номерлы боерыгы белән расланган формалар буенча 2021 ел өчен энергетика декларацияләрен, шул исәптән ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре (булганда) буенча бирүне тәэмин итәргә.

2022 елның 1 июленә кадәр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Алар куллана торган дизель һәм башка ягулыкның суммар күләме, мазут, табигый газ, җылылык энергиясе, электр энергиясе, күмер, шулай ук алар куллана торган су күләме чагыштырма шартларда дәүләт (муниципаль) учреждениеләре тарафыннан киметүгә

таләпләр турында» 2019 елның 7 октябрендәге 1289 номерлы карары нигезендә ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре киселешендә алар тарафыннан 2022 - 2023 еллар чорына кулланыла торган ягулык-энергетика ресурсларының суммар күләме чагыштырма шартларда киметүне тәэмин итү буенча чаралар планыу эшләргә һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына тапшырырга (алга таба - ресурслардан файдалануны киметүнең максатчан дәрәҗәсе).

2022 елның 1 августына кадәр Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Дәүләт һәм муниципаль берәмлек, эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы оешмалар катнашында оешмаларның энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге программалар рәвешенә һәм аларны гамәлгә ашыру барышы турында хисап таләпләрен раслау хакында» 2014 елның 30 июнендәге 398 номерлы боерыгы нигезендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү буенча элек расланган программаларны, шул исәптән ведомство карамагындагы дәүләт учреждениеләрен (булган очракта) эшләүне яисә корректировкалауны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

хисап кварталыннан соң килә торган айның 25енә кадәр ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләрнең энергия нәтиҗәлелеге күрсәткечләре буенча мәгълүматны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына квартал саен бирүне тәэмин итүне;

законнарда билгеләнгән срокларда Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Энергетика ресурсларын куллану турында декларация бирү тәртибен һәм энергетика ресурсларын куллану турында декларация формасын раслау хакында» 2019 елның 28 октябрендәге 707 номерлы боерыгы белән расланган формалар буенча 2021 ел өчен энергетика декларацияләрен, шул исәптән ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләр (булганда) буенча бирүне тәэмин итәргә.

2022 елның 1 июленә кадәр:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре тарафыннан алар куллана торган дизель һәм башка ягулыкның, мазут, табигый газ, җылылык энергиясе, электр энергиясе, күмернең суммар күләмен, шулай ук алар куллана торган суның күләмен чагыштырма шартларда киметүгә таләпләр турында» 2019 елның 7 октябрендәге 1289 номерлы карары нигезендә ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләр кысаларында ресурслардан файдалануны киметүнең максатчан дәрәҗәсенә ирешүне тәэмин итү буенча чаралар планын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына тапшырырга;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә региональ һәм муниципаль программаларга таләпләрне раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 11 февралендәге 161 номерлы карары нигезендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча элек расланган муниципаль программаны эшләүне яисә корректировкалауны тәэмин итәргә;

2022 елның 1 августына кадәр Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Дәүләт һәм муниципаль берәмлек, эшчәнлекнең җайга салына

торган төрләрен гамәлгә ашыручы оешмалар катнашында оешмаларның энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге программалар рәвешенә һәм аларны гамәлгә ашыру барышы турында хисап таләпләрен раслау хакында» 2014 елның 30 июнендәге 398 номерлы боерыгы нигезендә ведомство карамагындагы муниципаль учреждениеләрнең энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү буенча элек расланган программаларын эшләүне яисә корректировкалауны тәэмин итәргә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Энергия саклау технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү программаларын эшләгәндә (корректировкалаганда), шулай ук энергия сервисы контрактлары төзү юлы белән энергия саклау чараларын әзерләгәндә һәм гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә методик һәм консультация ярдәме күрсәтергә.

6. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынучы башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән берлектә, энергетика нәтиҗәлелеге һәм энергетиканы үстерү буенча «Россия энергетика атнасы» халыкара форумында һәм #ВместеЯрче бөтенроссия энергетика саклау һәм экология фестивалендә Татарстан Республикасының катнашу мөмкинлеген эшләргә.

7. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына энергетика нәтиҗәлелеге һәм энергетиканы үстерү буенча «Россия энергетика атнасы» халыкара форумында һәм #ВместеЯрче бөтенроссия энергетика саклау һәм экология фестивалендә Татарстан Республикасы катнашуын массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын 2020 елда тормышка ашыру барышы һәм 20121 елга бурычлар турында» 2021 ел, 09 июнь, 444 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

9. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин